# ИЛНЕҢ ИРТӘГӘСЕ БУЛЫР БУЫН

## ТЕЛГӘ МӘХӘББӘТ БЕЛӘН

*Килгән чакта башка авырлык,*
*Җитми калса көч һәм сабырлык,*
*Сиздермичә ярдәм иткәнсез -*
*Сез иң күркәм кеше икәнсез.*

Фәнис абый Яруллинның инде күптән танылырга өлгергән бу шигырь юлларын олы рәхмәт хисе рәвешендә Фома урта мәктәбе ана теле укыткан Рәзинә Гарифовна Сәлахова белән Резидә Дамировна Сафиуллина да бер генә тапкыр ишетмәгәндер, дип уйлыйм.

Рәзинә Гарифовна укытучылык эшен Түбән Нурлат авылында башлап җибәрә. Аннан Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Фомага килеп урнаша һәм балаларның сөекле укытучысына әверелә. Менә инде 24 еллап ул балалар белән эшли, ана телен укыта, укытучы - методист буларак, башкаларны да балалар белән эшләүнең нечкәлекләренә төшендерә.

Ә Резидә апага килгәндә, ул Казан дәүләт педагогия институтын бетереп, туган авылына кайта, һәм инде 9 елга якын татар теле һәм әдәбияты дәресләрен алып бара. Хәзерге вакытта өлкән укытучы ул.

Укытучының хезмәтен еш кына укучыларның белеме аша билгелиләр. Ә Рәзинә Гарифовна белән Резидә Дамировнаның укучылары ана теле һәм әдәбияты дәресләренә чыннан да яратып йөриләр. Яратмасалар, инде менә ничә ел рәттән ана теле буенча район олимпиадаларында призлы урыннар ала алмаслар иде. Ә соңгы елларда республика күләмендә үткәрелгән олимпиадаларда, "...Рус белән тормыш кичердек сайрашып, Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып...", "Республикам минем Татарстан" кебек конкурсларда да катнашу бәхетенә иреште Фома мәктәбе. Анда да призлы урыннар яулады, алдынгылар рәтенә чыкты ул. Болар нәкъ менә Рәзинә Гарифовнаның балалар белән эшләвенең нәтиҗәлелек күрсәткечләре, минемчә.

Укучыларда туган телгә генә түгел,ә һөнәренә карата да мәхәббәт уята беләләр алар. Чөнки соңгы 1 - 2 елда гына да Фома мәктәбен тәмамлаучылар арасында укытучы булырга теләгән, дөресрәге, ана теле укытучысы һөнәрен сайлаган укучылар шактый. Алар Казан, Алабуга югары уку йортларында белем үрләрен яулыйлар.

Әйе, укытучының дәрәҗәсе зур. Әмма һәрбер баланың меңләгән соравына канәгатьләнерлек җавап табу, һәрберсенә аерым игътибар бирү, шәхес тәрбияләү җиңел түгел. Моның өчен киң күңелле, сабыр - түземле, бала җанлы булу кирәктер, мөгаен. Һәм иң мөһиме - балаларны аңлый белү, һәрберсен аерым шәхес итеп караудыр. Ә Рәзинә Гарифовна белән Резидә Дамировна нәкъ шундыйлардан дип уйлыйбыз.

**Х.САФИУЛЛИН,**
**Фома урта мәктәбе директоры.**

## БАР ЯКТАН ДА КИЛГӘН УЛ

Фәридә Салиховнага карыйсың да, еш кына гаҗәпкә каласың. Шулкадәр өлгер булыр да икән кеше! Иртән иртүк эшкә ашыга: сукмагы көн саен мәктәпкә китерә аны. Хезмәттәшләре, укучылары каршы ала аны биредә. Юк - бар эшкә вакыты бер дә калмый үзенең. Сөйләшкән сүзе укучылары турында, бөтен борчу - кайгысы да шуларга багышланган. Һәм менә инде 15 еллап шулай. Хезмәт елларының соңгы унысы дүртенче мәктәп белән бәйле. Әлеге учреждение ачылуга ук килде ул бирегә. Беренче көннән үк җиң сызганып эшкә кереште. Шуңадыр, Фәридә Салиховнаның тәүге уңышы бер дигән, үрнәк булып торырлык математика кабинеты җиһазлавында булса, хезмәттәшләре әлеге хатын - кызның зур эш сәләтен, үзенә һәм башкаларга карата зур таләпчәнлеген дә күрми кала алмадылар. Укытучының педагогик уңышлары да озак көттермәде: берничә елдан ук ул укыткан укучылар математика фәне буенча мәктәп күләмендәге фән олимпиадаларында кыю җиңү яулап, район масштабында да призлы урыннарга чыга башладылар. Балалар белән уртак тел табып, аларның сәләтен юнәлешле үстерү өстендә һәрдаим иҗади эзләнеп эшләү нәтиҗәсе дип кабул иттеләр моны хезмәттәшләре. Ә укытучының исә коллективта абруе үсте, ныгыды. Хәзер ул мәктәпнең иң белемле укытучыларының берсе. Фәридә Салиховнаның менә инде өч ел рәттән математиканы тирәнтен өйрәнүче балалар белән эшләве дә шуның дәлиле.



Аның җитәкчелегендәге классның мәктәптә белем дәрәҗәсе, шулай ук öешканлык ягыннан иң әйбәте булуы да күп нәрсә турында сөйли. Шулай булмый ни: Фәридә Салиховна киң эрудицияле укытучы булуыннан тыш, алар өчен башка яклап та үрнәк бит. Актив рәвештә спорт белән шөгыльләнә ул. Системалы рәвештә бассейнга йөри. Мәктәпнең хатын - кыз укытучыларыннан торган командасында Ф.Лукъянова иң оста волейболчылардан санала. Килешик, киеренке укытучы хезмәтен шулай актив тормыш белән тулы канлы итеп үреп алып бару һәркемнең дә хәленнән килә торган нәрсә түгел. Төгәллек, көчле рухы, максатчанлыгы белән ирешә ул моңа дияр идем мин. Шулай булгач, Фәридә Салиховнаның өлгерлегенә, булганлыгына ничек сокланмыйсың ди инде?!

Сүз уңаенда Ф. Лукъянованың уңган хуҗабикә булуын да әйтми мөмкин түгел. Өч бала анасы ул. Улларының өчесенең дә һәрчак тамаклары тук, өсләре бөтен. Әниләре пешергән һәм һәрчак телеңне йотарлык булган ризыклар ашыйлар алар. Ә Фәридә Салиховнаның оста куллары белән пешерелгән тәмле пирог - күмәчләрне коллективта татып карамаган кеше юктыр, мөгаен.

Менә шундый уңган, булган, бөтен яктан килгән кешебез ул безнең.

**Р.ГИНЯЕВА,**
**4нче мәктәп директоры.**

**Рәсемдә: өлкән укытучы Ф.С.ЛУКЪЯНОВА.**

### САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

** Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә эшләүче 275 педагогның өчесе - югары, 33се - беренче, 114е - икенче квалификация категориясенә ияләр, 20се - мәгариф отличнигы.*

** Районда сәләтле балалар белән эшләү яхшыра. 2315 укучы узган ел факультатив занятиеләргә йөрделәр, 24 мәктәптә 918 укучы фәннәрне тирәнтен өйрәнү белән шөгыльләнде.*

*Хезмәттәшебез турында*

## ИГЕЛЕКЛЕ, ТАЛӘПЧӘН, ГАДЕЛ



Ярдәмче - интернат мәктәпкә төрле кеше төрле юллар белән килә эшкә: берәүләр хезмәт юлын биредә башлый, икенчеләр инде төрле мәктәпләрдә эшләп тәҗрибә туплагач күчәләр. Барысы да торып та калмый монда-эшләве авыр .

Вәсимә Нурмөхәммәт кызы Атауллина (рәсемдә) интернатка килгәнче күп мәктәпләрдә эшләгән (нишлисең, иреңне бер урыннан икенче урынга күчереп йөрткәч). Биредә башта тәрбияче була ул, аннары математика укыта. Педагоглык стажы 34 ел инде. Аңа һәрвакытта да игелеклелек, таләпчәнлек һәм гаделлек хас. Кул астындагыларга карата да кайгыртучан мөнәсәбәттә. Кул эшләренә оста булганга, бар белгәнен балаларга да өйрәтә. Хәзер ул мәктәптә хезмәт тәрбиясе дәресләрен алып бара. Тегү эше дәресләре уза торган мастерской менә дигән иттереп җиһазланган. Кызлар бу эшне яраталар, шуңа күрә дәресләр дә җанлы һәм кызыклы булып уза. Укытучы балалардан теге яки бу биремне аңлап башкаруларын да, теккән әйберләре чиста һәм матур булып килеп чыгуы турында кайгыртуларын да, пөхтәлек тә, куркынычсызлык техникасы таләпләрен белүләрен һәм үтәүләрен дә таләп итә. Программаның барлык бүлекләре буенча да кирәкле үрнәкләр, таблицалар, дидактик материал бар. Мәктәп үзе биргән заказлар һәрчак вакытында һәм сыйфатлы иттереп башкарыла.

Вәсимә Нурмөхәммәтовна мәктәптә бәйләү түгәрәге дә алып бара, укучыларга эстетик тәрбия бирү эшенә зур игътибар итә. Түгәрәккә йөрүчеләр чиккән әйберләр мәктәпкүләм һәм район күргәзмәләренә куелып призлы урыннар ала, ярминкәләрдә дә тиз сатылып бетә.

Педагог балаларга белем бирү белән генә чикләнми, класстан тыш чараларны да күп оештыра, тематик кичәләр, КВНнар, кызыклы язмышлы кешеләр белән очрашулар уздыра.

Кеше белән бик аралашучан, яхшы күңелле һәм таклы Вәсимә Нурмөхәммәтовна һәр баланың күңеленә ачкыч таба белә, алар аны игелекле, әниләрчә ягымлы һәм гадел булганы өчен яраталар, хезмәттәшләре арасында да абруйлы ул. Алга таба да иҗат уңышлары һәм яңа казанышлар телибез сезгә, Вәсимә Нурмөхәммәтовна.

**Н.МИННЕБАЕВА,**
**интернат - мәктәп завучы.**

## БЕЛЕМ БАСКЫЧЛАРЫ

Өченче мәктәпнең 3 нче сыйныфында чыгарылыш кичәсе бара.

- Нателла Бекоева хәзер сезгә "Көрәш" дигән юмореска сөйләячәк, - дип игълан итә кичәне алып баручы Наташа Самойленко.

Икәүнең ничек үҗәтләнеп көрәшүе турында бик матур иттереп сөйләп бирә Нателла. Башта ул көрәш ике кеше арасында бара төсле тоела, ә ахырдан сүзнең песи балалары турында икәнлеге беленә.

Аннан Зина Пируашвили әби белән оныгының маҗаралары турында сөйләде. Аннары күңелле музыка астында биюләр китте. Тамашачылар һәр чыгышны алкышладылар.

Саубуллашу кичәсе шулай уңышлы килеп чыкты һәм монда укытучы Валентина Петровна Жулинаның өлеше зур. Шуңа да бүген аның хакында бер - ике авыз сүз әйтәсе килә.

Валентина Петровна - Нурлат кызы, ике дистә елдан күбрәк вакыт элек шушы мәктәпне, аннан Алабуга педагогия институтын "кызыл" дипломга тәмамлаган. Аңа өлкән классларда дәресләр алып барырга тәкъдим итәләр. Әмма тәҗрибәле укытучы Зоя Федоровна Самойлованың киңәше белән беренче сыйныфны ала ул. Аларны укытып чыгаргач, тагын шундый цикл кабатлана. Аның мәгариф баскычлары әнә шулай салына башлый.



Укыту барышында балалары аңа шулкадәр якынаялар ки, алардан аерыласы да килми хәтта. Менә шушы классны гына алыйк. Гимназия классы дип йөртелә ул, катлауландырылган программа буенча укытыла. Ә бу исә укытучыдан да тирән белем сорый. Шуңа да әледән - әле дәреслекләр актарырга туры килә аңа, шул ук Зоя Федоровнаның дәресләрендә дә еш була. Курсларга һәм семинарларга да бара.

Валентина Петровна балаларның сәләтләрен иртә ачыклап үстерүгә зур игътибар бирә. Ринат Сәлахов, мәсәлән, рәсем ясарга, агачтан төрле фигуралар сырларга ярата. Сергей Цыганов шигырь сөйләргә оста. Лилия Гобәйдуллинаның сәләтләре дә искиткеч...

Укытучы шәкертләренең язмышлары белән дә кызыксынып тора. Ул укыткан балалардан укытучылар да, инженерлар да, гомумән яхшы кешеләр чыгу турында горурланып сөйли ул.

- Миндә белем алган Елена Рукавишникованың, Алия Галиуллинаның уңышлары белән горурланам мин,- ди.

Күптән түгел Валентина Петровна белән очрашкач, яңа уку елына планнары белән кызыксындым мин.

- Тагын яңа баштан башларга туры килә, - диде ул. - Гәрчә, бу беренчеләр дә минем өчен яңа түгел инде. Балаларның барысы белән дә, эти - әниләре белән дә әллә кайчан таныш. Кирәкле уку әсбаплары сайлауда булышам. Быелгылар белән дә уртак тел табарбыз, уңышларыбыз да булыр дип уйлым... Тик быел гына укытып чыгарганнарым барыбер җанга якынрак әлегә.

**Ф.САВГАЧЕВ.**

# БҮГЕН СЕЗНЕҢ КУЛДА, УКЫТУЧЫ!

Таныш исемнәр

Валентина Николаевна Сандрюхина 32 еллык педагогик эшчәнлегенең 22 елын Абрыскино башлангыч мәктәбен җитәкли. Күп еллар дәвамында бу коллектив балаларның белемгә омтылышын күтәрү, үзлегеннән эшләүләрен арттыру өстендә шөгыльләнә һәм уңай нәтиҗәләргә ирешә: мәктәптә өлгермәүчеләр һәм икенче елга калучылар юк. Валентина Николаевнаның укучылары урта мәктәптә укыганда район, республика күләмендәге конкурс һәм олимпиадаларда катнашалар, аннан пед.вузларда, техникумнарда белем алалар һәм инде үзләренең туган мәктәпләрендә укыталар, район һәм республика мәгариф учреждениеләрендә эшлиләр.

Абрыскино мәктәбе милли(чуваш) программа буенча шөгыльләнә. Әмма укучылар рус телен дә әйбәт беләләр. Татар телен 1нче класстан башлап өйрәнүгә дә зур әзерлек алып барыла. Мәктәптә әйбәт кенә методик почмак оештырылган, уку - тәҗрибә участогы бар. Кечкенә музей төрле экспонатлар белән тулыландырыла. Бу эштә укучылар да, укытучылар да катнаша. Киләчәктә мәктәптә яңа дәрес - палеология кертергә җыеналар, база хуҗалыгы ярдәмендә спорт комплексын тулыландыралар.

## ВАЛЕНТИНА НИКОЛАЕВНАНЫҢ МЕҢ ДӘ БЕР ЭШЕ



Газлаштыру көтелгәнгә, соңгы биш елда бик күп эшләргә туры килде. 1996 елда мәктәп беренчеләрдән булып газ белән җылытуга күчте, һәм монда кечкенә комплектлы мәктәп мөдирләре, КМБ укытучылары, ПМБ һәм район мәгариф бүлеге вәкилләре катнашында тәҗрибә уртаклашу максатында район семинары узды.

Тәҗрибәле педагог һәм җитәкче үзенең белемен күтәрүдән, туган телне тирәнтен өйрәнүдән туктамый һәм берничә тапкыр квалификация күтәрү курсларында булды, новатор укытучыларның тәҗрибәсен өйрәнә. Валентина Николаевна үзе дә яшь коллегалары белән эш тәҗрибәсен бик теләп уртаклаша, ачык дәресләр бирә, докладлар ясый, башлангыч класс укытучыларының секцияләрендә актив катнаша.

1996 елда В.Н.Сандрюхинага "Укытучы - методист" дигән квалификацион категория бирелде. Аның шәхси архивында - дипломнар, район мәгариф бүлеге һәм район хакимияте почет грамоталары. Үткән уку елында Абрыскино башлангыч мәктәбе "Ел мәктәбе - 98" Бөтенроссия конкурсында катнашып, лауреат исемен яулады. Җиңү белән Сезне, Валентина Николаевна!

**Л.ЕРМИЛОВА,**
**куст методик берләшмәсе җитәкчесе.**

**Рәсемдә: зур җиңү белән кайнар котлаулар.**



## Иҗади уйлап, мавыгып эшлиләр

Мәктәптә методик эш беренче чиратта предмет һәм башка төр методик берләшмәләрнең ничек эшләвенә бәйле. Бу җәһәттән мин башлангыч класс укытучылары Ю.П. Сөләйманова, Л.А.Григорьева, С.Н. Осипова һәм Т.В.Кузьминага аеруча рәхмәт сүзләре әйтер идем. Алар дәресләрен райондагы иң яхшы мәктәпләр тәҗрибәсен файдаланып, иҗади уйлап, кызыклы иттереп үткәрәләр, иҗат лабораторияләрен даими тулыландырып торалар. Аларга бер -берсенә ярдәмгә килү, педагогика яңалыклары белән уртаклашып тору, гомумән, үзара яхшы мөнәсәбәт хас. Балаларның әти - әниләре белән тыгыз элемтәдә тору да аларга эшләрендә нык булыша. Бу укытучылар гаилә белән мөнәсәбәтләрне тирәнәйтү максатыннан кулланыла торган формаларны санап чыгуы да кыен хәтта: җыелышлар, ял кичәләре, күңелле ярышлар, конкурслар һәм болай гына чын күңелдән сөйләшүләр... Шуңа да аларда белем алган балалар югары классларга инде күпкә катлаулы материалны да үзләштерергә әзер булып күчәләр.

Башлангыч класс укытучыларының кулларыннан килмәгән эш юк. Аларның кабинетлары - мәктәптә иң яхшылары. Безнең мәктәпнең башлангыч класслары базасында еш кына район семинарлары уздырылуы, аларның мәктәп һәм куст укытучылары өчен әледән -әле ачык дәресләр бирүе дә юкка түгел. Предмет берләшмәләренең һәр утырышы үз эшләренә гашыйк педагогларның шушы рәсемдәгечә (уңда - мәктәп директоры Т.А.Жилина) җанлы сөйләшүе рәвешендә уза.

**А.БЕЛОВА,**
**Егоркино урта мәктәбе директорының укыту - тәрбия эшләре буенча урынбасары.**

## ҺӘРКЕМГӘ ДӘ ҖЫЛЫ УЛ ЙОРТТА

***3 нче "Светлячок" ясле - бакчасы - райондагы мәктәпкәчә балалар учреждениеләре арасында иң күптәнгеләреннән. Аның ачылуына быел сентябрьдә 35 ел була. Коллективны Е.А.Вырдина җитәкли.***

Күп еллар инде коллектив балаларны тәрбияләүнең шәхескә ориентлаштырылган моделе өстендә эшли. Эштә төп юнәлеш - физик яктан да, психик, һәм интеллектуаль яктан да сәламәт бала тәрбияләү. Ә баланың сәламәтлеге тәрбия учреждениесенең тулаем эш системасына да, баланың мондагы мохитка яраклаша алуына да бәйле. Ә ул мохит менә дигән иттереп оештырылган предмет даирәсе дә, югары дәрәҗәдәге көнкүреш эстетикасы да, бинаның тышкы һәм эчке чисталыгы да, монда эшләүчеләрнең балаларга аналарча җылы мөнәсәбәте дә, педагогларның иң яңа методика буенча югары квалификацияле тәрбия һәм укыту алып барулары да дигән сүз. Бер дигән иттереп җиһазланган татар теле (Д.Ф.Йосыпова), логопед (Н.В. Морозова) кабинетлары, "Колорит" рәсем студиясе (Т.П.Корбанова), "Беләмән" экологик лабораториясе (Н.Н.Власова) дә, ДАИ бүлмәсе һәм мәйданчыгы да хезмәт итә моңа. Ясле - бакчада балаларның мавыгулары буенча "Сәхнә утлары" (Д.Ф.Йосыпова), "Бал корты" (М.П.Савельева) түгәрәкләре, аэробика (М.В.Нечаева), "Батыр" (Н.Н.Власова) группалары, "Рябинушка" инструменталь ансамбле (Л.Н. Бахчеева), "Тәмле" төркеме (О.П.Беглова), "Ак каен" һәм "Миләшкәй" вокаль ансамбльләре эшли.

Ясле - бакчадагы һәр төркемнең үз исеме генә түгел, үз йөзе дә бар. Бүлмәләрдә үз көчләре белән төрлечә бизәп эшләнгән җиһазлар куелган. Биредә эшләүчеләрнең үз куллары белән флористика стилендә ясалган эстамплар, паннолар бихисап. Предмет даирәсендә балаларга аларның психик сыйфатларын һәм акыл сәләтләрен үстерергә булышлык итүче читләтеп тәэсир ясау чаралары да кулланыла. Монда бар нәрсә балага уңайлы булсын өчен эшләнгән, аңа мәстәкыйльлек бирү өчен дә шартлар күп: үзе генә калып эмоциональ бушану: китаплар караштыру, курчак уйнау, хәтта чәй эчү яки алма ашап алу өчен дә мөмкинлекләр булдырылган. Балаларга үзләре яраткан эш белән шөгыльләнү өчен дә шартлар бар. Баланы бүтән беркем белән дә түгел, ә бары тик аның үзе белән генә, аның кичә нинди булуы, бүген нинди икәнлеге белән генә чагыштырырга мөмкин, балалар үз башлары белән уйларга, үз куллары белән эшләргә, үз телләре белән әйтергә теләсеннәр өчен балаларның янында түгел, ә алар белән бергә булырга кирәк, дип саныйлар монда. Уеннарның күпчелеге педагогларның үзләре тарафыннан уйлап табылган, ярдәмлекләр алдынгы технологияләр буенча нигездә үз куллары белән ясалган. Эштәге һәр минутның кадерен беләләр монда.

Ясле - бакчада берничә ел буе хәзерге заман педагогикасының иң популяр алдынгы технологияләрен кулланылышка кертү эше алып барыла. Кыскасы, "Светлячок" ясле - бакчасы коллективы укыту - тәрбия эшенең иң катлаулы бурычларын да хәл итәргә сәләтле, чөнки биредә коллективның перспективалары анда эшләүче һәркемнең шәхси перспективасы да булып тора.



**Р.ХӘСӘНШИНА,**
**район мәгариф бүлеге методисты.**

**Рәсемдә: ялгыз гына калып утырганда.**

## ТӘҖРИБӘСЕ БАЙ, ОСТАЛЫГЫ - ЗУР

Нәҗия Гарифовна Шәйхетдинованың балачак хыялы тормышка аша: 1977 елда, Казан Дәүләт пединститутын тәмамлап, Югары Нурлатка кайта ул. Шул елдан алып ул укучыларга математика фәне серләрен өйрәтә. Эшләү чорында ул үзен тырыш, эзләнүчән, тыйнак укытучы итеп танытты. Нәҗия Гарифовна - укучыларга ныклы һәм тирән белем бирү, аларда мөстәкыйльлек тәрбияләүне үзенә максат итеп куя һәм моның өстендә тырышып эшли. Логик фикерләү һәм телдән исәпләү күнекмәләрен ныгытуга аерым игътибар итә. Бу өлкәдә Нәҗия Гарифовна төрле дәрес формаларын уңышлы куллана. Болар: дәрес - КВН, дәрес - лекцияләр. Ә инде зачет дәресләр турында аерып әйтәсе килә. Зачет ике этапта: беренчесе - өйдә, практик эшләр, ә икенчесе - дәрестә, теория һәм практик эшләрне тапшыру.Зачетка әзерлек этабында укучылар мөстәкыйль рәвештә эзләнәләр, өйрәнәләр. Дәреснең мондый формалары теоретик белемнәрне практикада нигезле куллана белүгә йогынты ясый. Бу алым йомшак укучылар белән дә эшне җайлы оештырырга мөмкинлек бирә.

Мәктәптә эшләү дәверендә Нәҗия Гарифовна класс җитәкчесе буларак та үзен оста оештыручы итеп күрсәтте. Бу өлкәдә аның максаты дус, бердәм, ярдәмчел коллектив туплау иде һәм ул моңа уңышлы ирешә дә. Укытучының озак еллар эшләү тәҗрибәсе укучылар белән күп кызыклы чаралар оештырырга мөмкинлек бирә. Аның укучылар белән мөгамәләсе дә сокланырлык. Укытучының педагогик тәҗрибәсе бай, хезмәт нәтиҗәләре - һәрчак сөенерлек. Шуңа да, аның һәрьяклы әзерлеген, югары осталыгын искә алып 1997 - 98 нче уку елында аңа "Укытучы - методист" дигән квалификацион категория бирелде.

**Г.ӘҺЛИУЛЛИНА.**
**мәктәп директоры.**

### САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

** Райондагы 10289 укучының 4809ы -татар, 2863е -чуваш, 2508е-рус, 109ы - башка төрле милләт балалары.*

** 15 урта һәм 10 башлангыч мәктәптә, 10 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә белем һәм тәрбия бирү татар телендә алып барыла.*

** Районда эшләүче 1640 педагогның 910сы - югары белемгә ия, 230ы - читтән торып югары уку йортында белем ала. Һәр елны 50дән артык педагог читтән торып укырга керә.*

## ГАЗЕТА • УКУЧЫ • ГАЗЕТА • УКУЧЫ

# ЯХШЫЛЫК ҖИРДӘ ЯТМЫЙ

***Укучыларыбызны редакциягә төрле йомышлар китерә. Еш кына көнкүрештә килеп чыккан хәлләр сәбәп була. Һәм ул аңлашыла да, чөнки бу болганчык заманда бәлага таруың бик тиз һәм сине кем йолып калырын белә дә алмыйсың...***

Ә менә Валентина Васильевна Созонова безгә бөтенләй башка ният белән килгән иде: мунчасы бик тузган булган, һәм урман пункты аңа мунча салып чыгуда булышкан. Тол хатынның үтенеченнән йөз чөермичә, аңа ярдәм иткән өчен урман пункты башлыгы Анатолий Николаевич Семеновка рәхмәтләр укый ул. Материалын гына биреп калмаган, аны бер түләүсез китертеп тә биргән. Өй салырга ниятләгән башка кешеләргә дә булышмый калмый - кеше шәһәргә китәргә ашкынмый икән - хуҗалыкка эшче куллар арта дигән сүз бит. "Әз генә элегрәк шундый җитәкче куйган булсалар иде безгә, - ди Валентина Васильевна бераз көрсенү белән, - Тумбабыз тагын да ныграк булган булыр иде. Кешечә мөнәсәбәт булса, адәм баласы эшен дә рәтле иттереп эшли бит ул, урыннан - урынга күчеп йөрергә дә бик атлыгып тормый."

Бирелә производство мәсьәләләренә дә игътибарны йомшартмыйлар: эш күрсәткечләрен ирешелгәннәрдән киметмәскә тырышалар, агач утырту һәм урманнарны карап үстерүне дә күз уңында тоталар - шунсыз урман хуҗалыгының нинди киләчәге булсын ди?

Валентина Васильевна еректагы авыл һәм хуҗалык тормышы турында бик иркенләп, матур итеп, әмма шомартмыйча - нитмичә, ничек бар, шулай иттереп сөйләде. Үзе турында да әйтеп алды. 15 бала табып баккан ул. Аларны карап үстерү ничек авырга килгәнен бер үзе генә белә торгандыр. Әле барысы да башлы - күзле булып бетмәгәннәр, шуңа күрә ул хатынның мәшәкатьләре күпме икәнлеген чамалавы кыен түгел. Бәлки шуңадыр, кешенең түземлелеге, бер - береңне аңлау, бер - береңә әз генә булса да ярдәм итү кебек төшенчәләрнең кадерен бик яхшы белә ул. Күп балалы гаиләнең бюджеты әллә ни бай түгел, шуңа да Валентина Васильевна районның социаль яклау бүлегендә аларга бу ел өчен тиешле азык - төлек чекларын һәм жетоннарын биреп җибәрә алсалар, яхшы булыр иде дип өметләнеп кергән иде. Тик, кызганыч, күп балалы анага вакытында кирәкле киңәш бирүче булмаган. Әмма өметне өзәргә кирәкми әле, барысы да җайланыр дип уйларга кирәк.

Зур гаиләнең хуҗабикәсе Валентина Васильевна әнә шулай, тормышыннан зарланмыйча, көндәлек мәшәкатьләр чоңгылына кереп китмичә, күргән яхшылыклары һәм изгелекләре өчен тирә - ягындагыларга рәхмәт хисләре тулы күңеле белән яши.

**Т.АЛЕКСЕЕВА.**

## *Алло, редакцияме бу?*

### ДРУЖБА УРАМЫННАН ЕРАК КИТӘ АЛМАССЫҢ

- Алло, редакцияме әле бу?

Кормыш ягыннан Алексеева шалтырата сезгә. Бер мине генә түгел, Дружба урамы буйлап җәяү йөрергә мәҗбүр һәркемне борчый торган хәл турында әйтәсем килә. Әле былтыр көз үк монда, халыкның үтенече буенча, канализация торбаларын, сүүткәргечләрнең бер өлешен алыштырдылар. Кирәк эш, билгеле. Тик менә хикмәт шунда ки - НГДУ ОРСының "Ашамлыклар" кибетеннән алып урамда канау -чоңгыллар гына. Бульдозер белән тигезләп чыккан төсле дә булдылар, әмма мәгънәсе аз булды. Шуңа да кирәкле җиребезгә барыр өчен без әллә каян әйләнеп, Совет урамы аша йөрергә мәҗбүрбез. Коммуникацияләр сузу мәсьәләсе хәл кылынганда урамны асфальтлау, тротуарлар булдыру турында да сүз булган иде. Инде тагын көз җитеп килә бит - безнең урамга асфальт салыныр микән соң?

***Рәсми инстанцияләрдә безгә хәбәр итүләренчә, ул юлны төзү 1998 елга гомумшәһәр төзекләндерү планына кертелгән. Ул эшне НГДУ финанслар, ә башкаруын РСУ эшләр дип планлаштырылган. Көтеп карыйк әле тагын.***

### ЙӨК ҺАМАН ДА ШУЛ УРЫНДА

Кадерле редакция! Завод тыкрыгының 9нчы йортында яшәүчеләр яза сезгә. Йортыбыз яңа - өченче генә ел торабыз әле. Былтыр җәен йортка табигый газ тарта башлаганнар иде. Бер ай буе монтаж эшләре барды. Бригада Бөгелмәдән иде дип беләбез. Тик алар бер айдан юкка чыктылар. Дөрес, быел яз безне тагын исләренә төшерделәр бугай, монтаж эшләрен төгәлләп киттеләр. Начальниклары үзе фатир саен йөреп иске акча белән 400әр мең җыеп чыкты һәм 1 майга газ бирергә вәгъдә итте. Инде август җитте, челтәр газы төшебезгә генә керә әле. Бригада юкка чыкты, акчабыз начальникларында китте. Газчыларның кулланучыларга шундый мөнәсәбәтен ничек аңларга соң? Әллә сәбәп бүтәндәме?

**ГАЗИЗОВА,**
**МӘГЫЙЗОВА,**
**МУСИНА,**
**МӨХӘММӘДИЕВА,**
**МӨХӘММӘТШӘРИФОВА**
**һ.б. (Барлыгы 43 имза).**

### *УРАМ ЧАТЫН УРАП УЗАРЛЫК*



Гыйматдинов һәм Пушкин урамнары чатындагы су колонкасын былтыр ук алып ташлаганнар иде инде.

"Алып атуын аттылар, ә менә чокырын күмәргә оныттылар. Су агып ятуын да туктатучы булмады. Хәзер менә чоңгыл су белән тулып тора - бала - чага төшүе дә бик мөмкин (төшә язып калучылар булды да инде). Җитмәсә, почтаның иске бинасында яшәүчеләр сусыз да калды бит һәм халык чиләк күтәреп я мунча котельныена, я ит комбинаты янындагы колонкага йөрергә мәҗбүр. Күпме чыдарга мөмкин ди?"...

Редакциягә мөрәҗәгать итүче укучыларның зарлары шундыйрак. Мәсьәләгә ачыклык кертү максатында без МППга да мөрәҗәгать итеп карадык, тик конкрет җавап кына ала алмадык. Инде бу күренешне рәсемдә күрсәтү тәэсир итәр бәлки, дигән фикердә калабыз.

***Фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ берничә көн элек кенә төшергән фотода бу чоңгылдагы суны анализга аламы соң әллә бу кыз?!***


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР

**Александр Николаевич Сидоров исеменә документлар табучының бүләк бәрабәренә Циолковский ур., 13 -28 адресы буенча кайтарып бирүен сорыйбыз.**

***

**"Колос" ресторанында иртәнге 8дән төнге 2гә кадәр сыра бары эшли.**

***

*Рәхим итегез!*

**Гагарин урамында урнашкан "Чулпан" кибетендә "Чебурашка" балалар кафесы ачылды.**

Кафе иртәнге 8дән кичке 9га кадәр эшли.

***

**"Октябрь "Мелиорация"ПМКсы АҖнә бульдозер, скрепер, автокран машинистлары кирәк. Түләү - эш башыннан.**

***

**Файдаланган газ өчен түләмәү сәбәпле, Газпром РАҖсе табигый газ бирүне чикли. "Нурлатгаз" ЭПУсы да бурычларын түләмәүчеләргә газ бирү туктатылачагы турында кисәтә.**

Администрация.

**ФАТИР КИРӘК.**

**Фатир эзлим, Кормышта булса яхшы.** Тел.: 5-40-97.

**"Нурлат - Октябрь сөт - май комбинаты" АҖ барлык пенсионерларга пенсия исәбенә үзенең барлык кибетләрендә һәм автокибетләрендә сөт продуктларын түбәндәге бәяләрдә сата:**
- **пакетта сөт 2,5 % майлылык - 1,71;**
- **пакетта катык 3,2 % майлылык - 2,40;**
- **пакетта кефир 2,5 % майлылык - 2,04;**
- **пакетта каймак 20 % майлылык - 9,40;**
- **төргәктә майсыз эремчек - 5,68;**
- **үлчәүле крестьян мае - 19,50;**
- **төргәктә крестьян мае - 22,50.**

**Барлык пенсионерларга да үзләре белән пенсия кенәгәләре һәм паспорт алып килергә.**

Администрация.

***"Нурлат сәүдә базасы" АҖнә ашыгыч төстә даими эшкә газ хуҗалыгы өчен җаваплы (эш стажы булган) кирәк.***

***7нче кибетнең 2нче катында урнашкан сәүдә комплексы (шикәрчеләр поселогы) теләсә нинди тегү эшләре башкара.***

Нурлат райпосы идарәсе.

## БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Оешма түбән бәядән "Стинол" суыткычлары сата: "Стинол - 101L " - 2070 сум, 102L - 2900 сум, 107L - 2470 сум, 116L - 2285 сум, 110L - 2640 сум. Шулай ук ГАЗ -53 автомашинасы (будка) сатыла, бәясе килешү буенча, бартер да мөмкин.**

Автовокзалда "Автозапчастьлар" кибетенә мөрәҗәгать итәргә, тел.: 2-33-64 (эш), 2-14-99(өй).

***

**"Запорожец".** Тел.: 3-42-44, 2-15-99.

***

**Йорт.** Богдашкинода С.А.Максимовка мөрәҗәгать итәргә, тел.: 2-32-50, кичке 7дән соң.

***

**Кызыл кирпеч, кыйммәт түгел.** Тел.: 2-26-33.

***

**Ашыгыч төстә Совет ур.,119 - 13 адресы буенча бер бүлмәле фатир.**

***

**Шикәр заводы микрорайонында 2 бүлмәле фатир, азык - төлек комбинаты ягында базы белән гараж.**

Тел.: 2-22-38.

***

**"Москвич" .** Тел.: 5-22-79.

***

**Иске Чаллыда дача.** Тел.: 5-19-92.

***

**Овражная урамында 13нче йорт. Мунчасы,бакчасы, йорт яны корылмалары бар, суы кергән.**

Адрес: Овражная ур., 13, теләсә кайчан.

***

**Нурлат райпосы җәмәгать туклануы предприятиесе "Колос" рестораны каршында бүлеп ассортиментта әйбәт сыйфатлы сыра сата.**

Безнең барга килегез!

***

**Чанада гараж.** Адрес: Циолковский ур., 11 - 59.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Куйбышев урамында йорт сатыла яки фатирга алмаштырыла.** Тел.: 5-12-26, 2-22-16, көндезге 2 дән соң.

***

**3 бүлмәле фатир сатыла яки 2 һәм 1 бүлмәлеләргә алмаштырыла.** Тел.: 5-13-45.

***

**КАВЗ - 327101 автобусы 1 бүлмәле фатирга алмаштырыла яки сатыла.** Тел.: 5-32-56.

***

**Данәсен 3 сумнан керамзит блоклар сатабыз. Керамблокларны 1993 елгыдан да искерәк булмаган "ПАЗ" яки "КАВЗ" автобусына (йөреп торган булмаса да ярый) алмаштырабыз.** Димитровград шәһәрендә "Алиса" кибете артында "Сельхозхимия"нең элекке базасына мөрәҗәгать итәргә, тел.:(84235) 3-06-41.

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Менделеев шәһәрендәге 2 бүлмәле фатирны - Нурлатта яки Әлмәт шәһәрендә шуңа тиңгә.**

Әлмәттә тел.: 2-81-93, Нурлатта адрес: К.Маркс ур., 29- 8.

***

**Ике бүлмәле фатирны - өстәмә түләп бер бүлмәлегә.** Адрес: К.Маркс ур., 11 - 11.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**10тонналы КамАЗ, ГАЗ автомашиналарында йөкләрегезне ташыйбыз.** "Альянс" кибетенә мөрәҗәгать итәргә.

**"Альянс" кибете (азык -төлек базары) һәм "Елена" кибете (кием - салым базары) теләсә нинди модельле "Стинол", "Норд" суыткычлары (17 төрдә), туңдыру камералары, ларлар, витриналар сата. 2 елга гарантия, өстәмә түләүсез китереп бирү. Сатуда кимителгән бәядә телевизорлар, магнитофоннар, музыкаль үзәкләр һәм башка көнкүреш техникасы бар.**

Тел.: 5-41-19. Б-621 таныклыгы.

***Фомада яңа мәчет салына. Барлык якташларыбызга, авылдашларга, изге күңелле кешеләргә гыйбадәт йортын төзүдә хәлдән килгәнчә булышуларын сорап мөрәҗәгать итәбез.***

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга 28 нче август көнне, көндезге сәгать 11дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән

№ 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2353 данә. 3306